ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**02.05.2017** **Казан** **№ 26**

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә кайбер вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында**

“Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе мәсьәләләре” 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе турында нигезләмә нигезендә

**Б О Е Р Ы К  Б И Р Ә М:**

1. Түбәндәге кушымталарны расларга:

– төзүченең һәм проект декларациясенең “Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) рәвешен;

– бәяләмә бирүдән баш тарту рәвешен;

– бәяләмәләрне һәм мондый бәяләмәләрне бирүдә баш тартуларны теркәү журналы рәвешен.

2. Бу Боерык проект декларациясенең, проект декларациясенә үзгәрешләрнең төзүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенә (алга таба – Инспекция) җибәрелүе мәсьәләләрен җайга сала.

3. Проект декларациясе төзүче турында мәгълүматны һәм төзелеш проекты турында мәгълүматны үз эченә ала һәм төзүченең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акча чараларын җәлеп итүгә хокуклары күләмен билгели. Проект декларациясе төзүче өчен үзе артыннан юридик нәтиҗәләр китереп чыгара торган фактларны таныклаучы рәсми документ булып тора.

4. Проект декларациясенең эчтәлеген һәм проект декларациясенә үзгәрешләрне карау өчен нигез булган юридик факт – төзүче тарафыннан кәгазьдә һәм электрон версиясендә проект декларациясен яисә проект декларациясенә үзгәрешләрне Инспекциягә тапшыру.

5. Инспекциянең Хокук идарәсенең административ тәҗрибә һәм өлешле төзүне тикшереп тору бүлегенә:

– төзүченең “Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ Федераль закон) 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүен тикшерергә;

– төзүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүен тикшерү нәтиҗәләре буенча йә бәяләмә проектын, йә мондый бәяләмәне бирүдән нигезләнгән баш тарту әзерләргә;

– шушы боерыкта расланган рәвештә бәяләмәләрне һәм мондый бәяләмәләрне бирүдән баш тартуларны теркәү журналын электрон рәвештә теркәү юлы белән, бирелгән бәяләмәләрне һәм аны бирүдән баш тартуларның исәбен алып барырга;

– ел азагында бәяләмәләрне һәм мондый бәяләмәләрне бирүдән баш тартуларны теркәү журналын бастырып чыгарырга, аңа Инспекция башлыгының беренче урынбасары, Инспекция башлыгы тарафыннан виза салынуны тәэмин итәргә һәм тегеп куярга.

6. Бәяләмәне, бәяләмә бирүдән баш тартуны әзерләүнең һәм бирүнең иң күп чоры Инспекция тарафыннан проект декларациясе алынган көннән башлап 30 календарь көне тәшкил итә дип билгеләргә.

7. Бәяләмәгә, бәяләмә бирүдән баш тартуга Инспекция башлыгы (башлыкның беренче урынбасары, яисә аның вазыйфаларын башкаручы зат) имза сала дип билгеләргә.

8. Бәяләмә алу максаты белән проект декларациясен тапшырганда төзүчеләрнең Инспекциягә бер үк вакытта төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ Федераль закон таләпләренә җавап бирүен раслый

торган бүтән документларны һәм белешмәләрне тапшырырга хокуклы булуын билгеләргә.

9. 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясының 2 өлеше нигезендә “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге сайтттa проект декларациясенең электрон рәвешен тутыруның техник мөмкинлеген тәэмин иткәнчегә кадәр, төзүче проект декларациясен, проект декларациясенә үзгәрешләрне Инспекциягә кәгазьдә һәм Microsoft Excel программасы форматындагы электрон рәвештә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Проект декларациясе рәвешен раслау турында” 2016 елның 996/пр номерлы боерыгы белән расланган һәм Инспекциянең http://gsn.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырылган үрнәк буенча җибәрә.

10. 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясы 2 өлеше 1 пунктчасындагы таләп 2017 елның 1 июлендә үз көченә керә дип билгеләргә.

11. Бәяләмә, яисә бәяләмә бирүдән баш тарту Инспекция тарафыннан аларга карата “Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының көче туктатылган, төзелеше муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган объектларга бирелә дип билгеләргә.

12. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Инспекция башлыгының беренче урынбасары И.Ф. Сафиуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
“02”05.2017 № 26 боерыгы
белән расланды

ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

________________________№____________
№____________________ _________________

Рәвеше

Төзүченең “Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә

“Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан

_____________________________________________________________
(проект декларациясе нигезендә объектның аталышы)
__________________________________ (алга таба – проект декларациясе)
объекты буенча төзүче__________________________________________
(төзүченең аталышы, аның урнашкан урыны, ИНН, ОГРН)
_____________________________________________(алга таба – төзүченең)
Инспекциягә 20__елның “__”__________ килгән проект декларациясе карап тикшерелде.

Төзүче һәм проект декларациясе 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә **җавап бирә**.

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
“02”05.2017 № 26 боерыгы
белән расланды

ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

________________________№____________
№____________________ _________________

Рәвеше

Төзүченең “Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту

“Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан____________________________________________
(проект декларациясе нигезендә объектның аталышы)
________________________________________ (алга таба – проект декларациясе)
объекты буенча төзүче________________________________________________
(төзүченең аталышы, аның урнашкан урыны, ИНН, ОГРН)
__________________________________________________(алга таба – төзүченең)
Инспекциягә 20__елның “__”__________ килгән проект декларациясе карап тикшерелде.

Төзүче һәм (яисә) проект декларациясе[1] 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән түбәндәге таләпләргә җавап бирмиләр (җавап бирми)[2]:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(төзүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәвенең, һәм (яисә) проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәвенең ачыкланган фактлары күрсәтелә)

[1] Кирәкле вариант калдырыла: төзүче һәм проект декларациясе, яисә төзүче, яисә проект декларациясе
[2] Бер вариант калдырыла

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.2 өлеше нигезендә Инспекция төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

*Бу баш тарту төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә алу максатында Инспекциягә проект декларациясен яңадан тапшыруга каршы килми.*

Башлык В.А. Кудряшов

ТР ДТК инспекциясенең
“02”05.2017 № 26 боерыгы
белән расланды

Рәвеше

Төзүченең “Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ Федераль закон) 3 статьясының 2 өлешендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмәләрне һәм мондый бәяләмәләрне бирүдән баш тартуларны теркәү журналы

| № п/п | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан проект декларациясен алу датасы | Төзелеш проектының аталышы һәм адресы | Төзүче (аталышы, ИНН) | Дата һәм документның № | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирүе турында бәяләмә | төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |